Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлеге Яңа Әлмәт авылы торак пунктында
гражданнар җыены КАРАРЫ

«15»ноябрь 2023 ел № 4

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Иске Әлмәт авыл җирлеге Яңа Әлмәт авылы торак пункты гражданнары җыены

КАРАР ИТТЕ:

2024 елда Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Иске Әлмәт авыл җирлеге Яңа Әлмәт авылы территориясендә яшәүче I төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм аларның толларыннан, көндезге бүлектә белем алучы студентлардан тыш, һәр балигъ булган кешедән 1500 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкару буенча мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлеге Яңа Әлмәт чикләрендә юлларны карап тоту, грейдировкалау һәм киләчәктә юл салу өчен өчен тыгыз нигез салу,

- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлеге Яңа Әлмәт чикләрендә юл полотносы профилен үзгәртеп, вак таш сатып алу, хезмәт күрсәтүләр өчен түләү.

Халык җыенында рәислек итүче Р.Г. Хисамов

Иске Әлмәт авыл җирлеге башлыгы Р.Г. Хисамов